| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

08.04.2020 ел          Баулы шәһәре          № 77

Мәктәпкәчә белем бирү программасын
тормышка ашыручы мәгариф
оешмаларына йөрүче балалары булган
гражданнарга компенсация
түләүләре вакытын озынайту

Коронавирус инфекциясе таралу куркынычын минимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль ярдәмнең аерым чараларын бирү срогын озайту турында» 2020 елның 1 апрелендәге 241 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Түләү чоры 2020 елның 30 сентябренә кадәр чыга торган социаль ярдәм чараларын бирү 2020 елның 1 октябренә кадәр озынайтырга. Моның өчен мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» 2013 елның 23 сентябрендәге 228 номерлы карары белән (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 августындагы 243 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) билгеләнгән мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен алу өчен гаризаны кабат тапшырырга кирәкми.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары И. И. Хөснуллинга йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе                    И.И. Гозәеров